ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**31.03.2023ел**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 944**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 28 нче августындагы 1715 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә махсус янгынга каршы режим билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2021 елның 21 декабрендәге «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 414-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 4,5 өлеше, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 28 нче августындагы 1715 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Тәртипнең 5 пунктындагы беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына (http://pravo. tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин